КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

__ _____ 2018 ел ________

Актаныш авылының су басуга каршы чараларын әзерләү һәм үткәрү чаралары турында

1. Актаныш авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясенең кушымтада бирелгән составын раслarга (1 нче кушымта)

2. 2018 елда Актаныш авыл җирлеге территориясендә язгы ташуны авариясез үткәрү буенча чараларның кушымтада бирелгән планын расларга (2 нче кушымта)

3. Су басуга каршы комиссия әгъзаларына куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм су басу турында халыкны вакытында хәбәр итү буенча чаралар күрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы И.Ш.Шәрапов

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Актаныш авыл башкарма
комитеты карарына
1 нче кушымта

Актаныш авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе составы

Шәрәпов И.Ш. - Актаныш авыл башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы, су басуга каршы комиссия рәисе;

Саетгалиев М.А.- «МУП полигон» директоры, су басуга каршы комиссия рәисе урынбасары;

Су басуга каршы комиссия әгъзалары:

Могътазиров Р.А. - «Актаныш РҮХ» баш табибы урынбасары;

Гиздатуллина Р.Ф. - Актаныш авыл җирлеге Советы депутаты, Актаныш 1 санлы урта мәктәбе директоры;

Нәгыймов Д.М. - Актаныш авыл җирлеге Советы депутаты, «Теплосервис» ҖЧҖ директоры;

Кустова Р.З. - Актаныш авыл җирлеге Советы депутаты, «Актаныш инженерлык челтәрләре» ҖЧҖ директоры.

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл башкарма комитеты карарына 2 нче кушымта № ___

2023 елгы язгы ташу чорында  Актаныш муниципаль районы халкын һәм территориясен саклау чараларының планы

| т/б | Чараның атамасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|
| 1 | Язгы ташу чорында «Мәликә», «Хәмит» «Җидегән чишмә», «Изгелар» чишмәләренең үзәкләштерелгән су белән тәэмин ителешен контрольдә тотуны көчәйтергә. | Авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе |
| 2 | Су басу чоры башланганда дежурлык оештырырга һәм көн саен Актаныш муниципаль районы гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия рәисенә хәбәр итәргә. | Авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе |
| 3 | Су басуга дучар булган торак пунктлар халкы өчен вакытлыча эвакуация пунктлары әзерләргә | Авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе |
| 4 | Су әзерләү процессында һәм су басу ситуациясен исәпкә алып, эчәр суның сыйфатына җитештерү контролен гамәлгә ашырырга. | Авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе |
| 5 | Актаныш торак пунктының контейнер мәйданчыкларын карап тотуны һәм территорияләрен төзекләндерүне контрольдә тотуны көчәйтергә. | Авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе |
| 6 | Үзәкләштерелмәгән су белән тәэмин итү системаларының (чишмәләрнең) суын системалы рәвештә зарарсызландыруны гамәлгә ашырырга. | Авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе |
| 7 | Язгы ташу чорында эпидемия ягыннан мөһим объектларга контрольне көчәйтергә. | Авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе |

| | | |
|---|---|---|
| 8 | Актаныш авылы халкына инструктаж үткәрү | Авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе |
| 9 | Су басу зоналарыннан халыкны эвакуацияләү ихтималы өчен транспорт һәм биналар әзерләү. | Авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе |
| 10 | Боз һәм язгы ташуга бәйле чараларны гамәлгә ашыручы барлык хезмәткәрләргә инструктаж үткәрү | Авыл җирлегенең су басуга каршы комиссиясе |